**СОВЕТ ВЫСОКОГОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

Кооперативная ул., 5, пос. ж/д станция Высокая Гора, Высокогорский район, Республика Татарстан, 422700

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОН СОВЕТЫ**

Кооперативная ур., 5, Биектау т/ю станциясе поселогы, Биектау районы, Татарстан Республикасы, 422700

Тел.: +7 (84365) 2-30-50, факс: 2-30-86, e-mail: biektau@tatar.ru, www.vysokaya-gora.tatarstan.ru

---

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

**2 нче апрель 2021 ел** **№ 65**

## Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы авыл җирлекләренең җирле әһәмияттәге аерым мәсьәләләрне хәл итү вәкаләтләрен кабул итү турында

2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 15 статьясындагы 4 өлеше, «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Советы

**КАРАР БИРДЕ:**

1. Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы составына керүче авыл җирлекләре вәкиллекле органнарыннан Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Башкарма комитетына әлеге авыл җирлекләренең Башкарма комитетлары тарафыннан тапшыру турында җирле әһәмияттәге түбәндәге мәсьәләне хәл итү буенча вәкаләтләрне кабул итәргә:

- җирләүгә тарифларны билгеләү һәм җирләү һәм күмү эше өлкәсендә вәкаләтле җирле үзидарә органы вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өлешендә ритуаль хезмәт күрсәтүләрне оештыру буенча.

2. Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Башкарма комитетына әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән вәкаләтләрне Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының авыл җирлекләре Башкарма комитетлары белән, төзелә торган килешүләрнең гамәлдә булуы 2021 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагылуын күз алдында тотып килешү төзергә.

3. Әлеге карарны интернет челтәрендәге «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең рәсми сайтында: http://vysokaya-gora.tatarstan.ru/ адресы буенча һәм Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында: http://pravo.tatarstan.ru/ веб-адрес буенча бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

Совет рәисе,
Муниципаль район Башлыгы Р.Г.Кәлимуллин